**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2020 **Чирмешән авылы** **№499**

**«2021 елга Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районында**
**юл хәрәкәте иминлеген арттыру»**
**максатчан программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль программасы турында» 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы карары нигезендә, гражданнарның тормышын һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, аларның юллардагы имин хәрәкәт шартларына законлы хокуклары гарантияләрен арттыру максатларында, **КАРАР БИРӘМ:**

1. «2021 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасын расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

«Расланган»
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2020 елның 25 ноябрендәге
499 номерлы карары белән

**" 2021 ЕЛГА**
**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА**
**ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ ИМИНЛЕГЕН АРТТЫРУ"**
**МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ**

Чирмешән авылы

## ЭЧТӘЛЕК

Программа паспорты ……………………………………………… 3-5

I. Проблеманың характеристикасы ………………………………6-9

II. Программаларның төп максатлары һәм бурычлары ………9-12

III. Программаның чаралары исемлеге …………………………12-13

IV. Программаның ресурс тәэмин ителеше ……………………13

1 кушымта………………………………………………...............14-15

2 кушымта ……………………………………………….............16

3 кушымта ……………………………………………….............17

4 кушымта …………………………………………,,……............18

**"2021 елга Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру"**
**максатчан программасы**
**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | "2021 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" максатчан программасы |
| Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Программаны эшләү буенча карарын кабул итү датасы (тиешле норматив актның исеме һәм номеры) | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 25 ноябрендәге 499 номерлы карары |
| Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Чирмешән районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге |
| Программаның заказчылары | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Чирмешән районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге, «Мәгариф бүлеге» МКУ,<br>«Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль учреждениесе, «Чирмешән РҮХ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Татарстан Республикасы Чирмешән районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең ЮХИДИ бүлеге |
| **Программаның максатлары һәм бурычлары** | ***<u>Программаның максатлары:</u>*** юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны киметү;<br>зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү.<br><u>Программаның бурычлары :</u><br>- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү;<br>- транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләү һәм аларны юл хәрәкәтендә катнашуга кертү системасын үстерү;<br>- балалар арасында юл-транспорт имгәнүләрен киметү;<br>- шәһәрләрдә транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү;<br>- юл-транспорт һәлакәте урынына тиешле хезмәтләрнең килү вакытын кыскарту, юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- транспорт чаралары куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү; |

| | |
|---|---|
| | - федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген сизелерлек арттыру;<br>- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең хокукый нигезләрен камилләштерү;<br>- әлеге өлкәдә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне регламентлаштыруда җитешсезлекләр һәм каршылыкларны бетерү. |
| Мөһим максатчан күрсәткечләр һәм индикаторлар | Программаның мөһим күрсәткече:<br>- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны кимү;<br>- зыян күрүчеләр белән юл-транспорт һәлакәтләре саны кимү.<br>Программаның мөһим индикаторы:<br>- транспорт куркынычын киметү (юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны, 10 мең транспорт чарасына);<br>- социаль куркынычны киметү (юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны, 100 мең кешегә);<br>- нәтиҗәләрнең авырлыгын киметү (юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны, зыян күргән 100 кешегә);<br>- юл-транспорт һәлакәтләре концентрация урыннары санын киметү;<br>- транспорт чарасы белән идарә итү стажы 3 елдан артмаган машина йөртүчеләр катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны кимү;<br>- үз саксызлыгы аркасында юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән балалар саны кимү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2021 ел |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме тәшкил итә **- 4300,0 мең сум:**<br>район бюджеты хисабына **- 3100,0 мең сум**<br>«Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» ДБУ хисабына - **200,0 мең сум**<br>бюджеттан тыш чыганаклар – **1000,0 мең сум** |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2021 елга юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны 2020 ел белән чагыштырганда 2 тапкырга кимрәк. |

## I. Проблема характеристикасы

Автомобиль транспорты белән бәйле авария (алга таба - авария) проблемасы соңгы унъеллыкта юл-транспорт инфраструктурасының җәмгыять һәм дәүләтнең куркынычсыз юл хәрәкәте ихтыяҗларына туры килмәве, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү системасының җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәве һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның бик түбән дисциплинасы белән бәйле рәвештә аеруча кискенләшә бара.

Юл-транспорт һәлакәтләренең төп төрләре: җәяүлегә, киртәгә һәм транспорт чарасына бәрелү, шулай ук бәрелешү һәм әйләнеп каплану.

Барлык юл-транспорт һәлакәтләренең дүрттән бер өлеше Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуга бәйле. Барлык һәлакәтләрнең якынча өчтән бер өлеше хәрәкәт тизлеген дөрес сайламау белән бәйле. Һәр сигезенче юл-транспорт һәлакәте исерек хәлдә булган, һәр җиденчесе - транспорт чарасы белән идарә итү хокукы булмаган шофер белән башкарыла. Авариягә физик затларга караган транспорт чараларын йөртүчеләр төп йогынты ясый. Юл хәрәкәтендә катнашучыларның иң күп санлы һәм иң зәгыйфь төркеме булып җәяүлеләр тора.

Авариялелек һәм вәзгыятьнең алга таба начарлануына тенденцияләр булу белән бәйле катлаулы хәл күбесенчә түбәндәге сәбәпләр белән аңлатыла:

- халыкның мобильлеге даими артуы;
- җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүне киметү һәм шәхси транспортта пассажирлар йөртүне арттыру;
- автомобильләр саны арту һәм заманча транспорт агымнарына исәпләнмәгән урам-юл челтәре озынлыгы арасында диспропорция артуы.

Мондый хәлләрнең нәтиҗәсе: юл хәрәкәте шартларының начараюы, экологик хәлне бозу, тоткарлыклар саны, ягулык чыгымнары арттыру, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләренең саны арту.

Хәзерге вакытта шәһәрләрдә һәм торак пунктларда барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 70 проценттан артыгы бара. Шәһәрләрдә юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләр саны арту темплары юл-транспорт һәлакәтләре санын арттыру темпларын узып китә.

Хәзерге заман юл-транспорт травматизмы үзенчәлекләрен өйрәнү күрсәткәнчә, юл-транспорт һәлакәтләренең саны акрынлап арта бара, алар нәтиҗәсендә, зыян күрүчеләр аеруча авыр дәрәҗәдәге җәрәхәтләр ала. Мондый юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга медицина ярдәме күрсәтү эшен нәтиҗәсез оештыру, аларның югары үлеменә китергән төп сәбәпләрнең берсе булып тора.

Авариягә бәйле хәлнең катлаулануы һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасының булуы озак вакытка исәпләнгән стратегия эшләүне һәм тормышка ашыруны, җәмгыять тырышлыгын координацияләүне, җирле ресурслар концентрациясен, шулай ук гражданнарның мәнфәгатьләрен тулысынча исәпкә алганда башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләтнеке булмаган структураларның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәле механизмнарын формалаштыруны таләп итә.

**Еллар буенча ЮТҺ**

| Еллар | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | всего |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ЮТҺ | 23 | 20 | 11 | 22 | 7 | 16 | 23 | 14 | 136 |
| Һәлак булды | 5 | 9 | 3 | 6 | 1 | 3 | 4 | 3 | 34 |
| Яраланды | 28 | 24 | 14 | 26 | 8 | 19 | 27 | 16 | 162 |

Программа-максатчан методны кулланмыйча формалаштырылган юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү системасы комплекслы һәм башкарма хакимият органнары эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәле механизмы булмау белән характерлана, бу юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашырганда таркаулыкка китерә.

Кайбер норматив хокукый актларда башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары функцияләре кабатлана. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең кайбер өлкәләре җайга салынмаган. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нормалары хокук бозуларны кисәтү функциясен тулысынча тәэмин итми.

Килеп туган хәл юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә барган тискәре процессларга йогынты ясауның реаль рычагларын нәтиҗәсез куллану белән катлаулана. Кабул ителгән чаралар максатчан характерда түгел, бердәм бурычка буйсынмый һәм, нәтиҗә буларак, бу өлкәдә булган тискәре тенденцияләрне тамырдан үзгәртә алмый.

Юл-транспорт һәлакәте урынына килүне оештыру һәм юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасы нәтиҗәсез.

Юл хәрәкәтендә катнашучыларга дәүләт һәм иҗтимагый йогынтысы закон белән тотрыклы үз-үзеңне тоту стереотипларын формалаштыру максаты белән тиешле дәрәҗәдә башкарылмый. Ситуация гомум хокукый нигилизм, кылган хокук бозулар өчен юридик җавапсызлыкны аңлау, юл-транспорт һәлакәтләренең мөмкин булган нәтиҗәләренә битарафлык, юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу сәбәпләрен тиешле дәрәҗәдә аңламау булмау, халыкны юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү эшчәнлегенә тиешенчә җәлеп итмәү белән катлаулана.

Программа-максатчан метод булмау шартларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә килеп туган кискен вәзгыять аның алга таба начараюына тенденцияләр булу белән характерлана, бу түбәндәге факторлар белән билгеләнә:

- юл-транспорт һәлакәтләренең (шул исәптән балалар травматизмы) авариясе һәм нәтиҗәләре авырлыгының югары дәрәҗәсе. Шул ук вакытта 2021 елда юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган кешеләр саны кимү кәтелә кеше.
- юл - транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар арасында иң актив эшкә яраклы яшьтәге (26-40 яшь) кешеләрнең шактый өлеше;
- юл хәрәкәте шартларының начараюы дәвам итә;

- автомобиль транспортында пассажирлар йөртү иминлегенең түбән дәрәҗәсе.

Шулай итеп, программаны эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы түбәндәге сәбәпләргә бәйле:

- проблеманың социаль-икътисади кискенлеге;
- проблеманың тармакара һәм ведомствоара характеры;
- проблеманы хәл итүгә хакимиятнең башкарма органнарын һәм җирле үзидарә органнарын җәлеп итү зарурилыгы.

Бүгенге шартларда федераль дәрәҗәдә дәүләт ярдәменнән башка Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр үз территорияләрендә яшәүче халыкның тормыш иминлеген тәэмин итүгә булган ихтыяҗны нәтиҗәле канәгатьләндерә алмый.

Программа-максатчан методны куллану тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк:

- юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу сәбәпләрен тикшергәндә фәнни потенциалны үстерү һәм куллану, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалауның һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметүнең төп һәм өстенлекле юнәлешләрен формалаштыру;
- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;
- чаралар комплексын, шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре санын һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санын киметүче профилактик чараларны гамәлгә ашыру.

Шуның белән бергә, юл хәрәкәте иминлеген арттыру проблемасын хәл итү өчен программа-максатчан методны куллану билгеле бер куркынычлар белән бәйле. Шулай итеп, Программаны тормышка ашыру барышында программаның аерым чараларының аварияле лек һәм көтелә торган нәтиҗәлелек өлкәсендәге ситуациягә йогынтысы туры килмәве, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге бурычларны хәл итүдә яңа алымнар куллану, шулай ук Программаны гамәлгә ашыруның башлангыч стадияләрендә башкаручылар эшчәнлегенең тиешенчә җайга салынмаганлыгы аркасында, арадаш нәтиҗәләргә ирешүдә тайпылышларны ачыклау мөмкин.

Әлеге куркыныч белән идарә итү максатларында программаны гамәлгә ашыру барышында карала:

- программаның төп башкаручыларының функцияләрен, вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын төгәл бүлү нигезендә нәтиҗәле идарә итү системасын булдыру;
- программаны үтәү мониторингы, даими анализ һәм кирәк булганда индикаторларны һәм күрсәткечләрне, шулай ук Программа чараларын ел саен корректировкалау һәм ранглау;
- финанслау күләмнәрен, куелган максатларга ирешү динамикасына һәм темпларына, тышкы мохиттә үзгәрешләргә бәйле рәвештә, яңадан бүлү.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты - юл - транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган кешеләр санын 3 тапкырга, һәм 2016 ел белән чагыштырганда 2021 елда зыян күргән юл-транспорт һәлакәтләре санын 100 процентка киметү. Бу безгә халыкның алга киткән автомобилизациясе белән илләр өчен хас булган юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә якынаюга, авариялелек

күрсәткечләрен киметергә һәм, димәк, проблеманың социаль кискенлеген киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаның максатларына ирешү шартлары булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:

- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү;
- машина йөртүчеләрне әзерләү һәм аларны юл хәрәкәтендә катнашуга кертү системасын үстерү;
- балалар арасында юл-транспорт имгәнүләрен киметү;
- районда транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү;
- юл-транспорт һәлакәте урынына тиешле хезмәтләрнең килү вакытын кыскарту, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- транспорт чаралары куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү;
- идарә итүнең җирле дәрәҗәсендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә идарә итү системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең хокукый нигезләрен камилләштерү, әлеге өлкәдә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне регламентлаштыруда җитешсезлекләр һәм каршылыкларны бетерү.

Программаны бер ел дәвамында тормышка ашыру күздә тотыла.

2021 елга түбәндәге беренче чираттагы чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла:

- юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;
- юл хәрәкәтендә катнашучыларда үз-үзеңне законга буйсынучан тоту стереотипларын формалаштыруга юнәлдерелгән пропаганда кампанияләрен үткәрү;
- гражданлык җәмгыяте институтларын профилактик эшкә җәлеп итүне тәэмин итү;
- машина йөртүчеләрне әзерләү өлкәсендә лицензияләү системасын камилләштерү, "A" һәм "B" категорияләре транспорт чаралары белән идарә итү хокукын алу өчен гражданнар тарафыннан мөстәкыйль әзерлекне гамәлгә ашыруны контрольдә тотуның хокукый нигезләрен эшләү;
- транспорт чарасы белән идарә итү хокукы алуга кандидатлардан квалификация имтиханнарын кабул итүнең комиссия принцибын кертүнең норматив-хокукый һәм оештыру аспектларын эшләү;
- автомәктәпләргә карата машина йөртүчеләрне әзерләү сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирүче механизмнарны кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- гражданнарны транспорт чаралары белән идарә итүгә кертү мәсьәләсен хәл иткәндә яшь буенча чикләүләрне үзгәртү турында тәкъдимнәр әзерләү;
- Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тартылган транспорт чараларын йөртүчеләр турында мәгълүматларның мәгълүмат базасын булдыру;
- транспорт чараларының актив һәм пассив куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү;
- куркынычсызлык чаралары булуына, төзеклегенә һәм куллануына контрольне көчәйтү;
- балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалауны арттыру, балалар өчен тотып калучы җайланмаларны актив кертү;
- юл-патруль хезмәте постларын Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләрен юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан үтәүне контрольдә

тотуның техник автоматик системалары белән алыштыру буенча пилот проектларны гамәлгә ашыру.

- район юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясен техник яктан яңадан кораллландыру;

- транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру буенча эш күләмнәренең, шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе урыннарын бетерү буенча да эш күләмнәренең шактый артуы;

- урам-юл челтәре участокларында тиз хәрәкәт режимнарын оптимальләштерү, транспорт чаралары тукталышларын оештыру, юл хәрәкәтен оештыруның заманча инженер схемаларын, заманча техник чараларны (светофорлар, юл билгеләре, тамгалар һ. б.) һәм хәрәкәт белән идарә итүнең автоматлаштырылган системаларын куллану;

- машина йөртүчеләрне әзерләү өчен заманча автодромнар төзү буенча эш күләмен киңәйтү, аларны төзү өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирү мәсьәләләрен хәл итү;

- юл-транспорт һәлакәтләре турында мәгълүматны аларның нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы дежур хезмәтләргә оператив җиткерү механизмын камилләштерү, әлеге хезмәтләрне юл-транспорт һәлакәте урынына чакыру өчен бердәм номер кертү;

- юл-транспорт һәлакәте урынында дежур хезмәтләрнең үзара хезмәттәшлеге регламентын кертү;

- юл-транспорт һәлакәте урынында зыян күргән затларга беренчел медицина ярдәме күрсәтүнең оештыру һәм хокукый нигезләрен эшләү һәм юл-транспорт һәлакәте урынында эшләр башкаруда катнашучы хезмәт хезмәткәрләренә, шулай ук юл хәрәкәтендә катнашучыларга өйрәтү;

- район юл хәрәкәте иминлеге инспекциясенең юл-патруль хезмәтенең стационар постларын беренчел медицина ярдәме күрсәтү чаралары белән җиһазлау;

- юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгуның закончалыкларын, аларның илнең социаль-икътисадый үсешенә йогынтысы закончалыкларын ачыклауга, юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалауның өстенлекле юнәлешләрен нигезләүгә һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметүгә юнәлдерелгән системалы тикшеренүләр үткәрү;

- федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәләрдә юл хәрәкәте иминлеге системасы белән идарә итүнең оптималь модельләрен төзү;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актларны камилләштерү буенча эшләр үткәрү;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемаларын хәл итүдә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләүнең ролен арттыруның хокукый һәм оештыру механизмнарын эшләү;

- юл-транспорт травматизмы динамикасын, юл хәрәкәте иминлеге проблемалары буенча җәмәгатьчелек фикерен һәм Программа чараларын тормышка ашыру мониторингы.

- транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру буенча эш күләмен алга таба арттыру, шул исәптән юл хәрәкәтен оештыру, магистраль, район һәм гомумшәһәр әһәмиятендәге хәрәкәт белән идарә итү буенча комплекслы схемаларны һәм проектларын гамәлгә кертү;

- җир асты һәм җир өсте җәяүлеләр кичү юлларын төзү буенча эшләр күләмен киңәйтү;

- район юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясен яңадан җиһазландыру өчен заманча техник чаралар һәм яңа буын системалары булдыру буенча эшләрне дәвам итү;

- юл хәрәкәтендә катнашучыларда закон тыңлаучан тотышның тотрыклы стереотипларын формалаштыруга юнәлдерелгән пропаганда кампанияләрен дәвам итү;

- профилактик чаралар үткәрүдә иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның ролен арттыру;

- балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау буенча эшләрне камилләштерү;

- юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан билгеләнгән нормативларны һәм кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту һәм күзәтү формаларын һәм методларын камилләштерү;

- юл-транспорт травматизмы динамикасын, юл хәрәкәте иминлеге проблемалары буенча җәмәгатьчелек фикерен һәм Программа чараларын тормышка ашыруны мониторинглауны дәвам итү.

## III. Программаның чаралар исемлеге

Программа чаралары комплексы Программаның түбәндәге юнәлешләре буенча капиталь кертемнәр һәм башка ихтыяҗлар өчен чыгымнар статьялары буенча формалаштырыла һәм финанслана:

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын арттыруга һәм куркыныч тәртибен кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар 1 номерлы кушымтада китерелгән.

Әлеге юнәлештә эшчәнлек транспорт чараларын йөртүчеләрне, юл хәрәкәтендә башка катнашучыларны әзерләү системасын камилләштерү һәм үстерүне, Россия Федерациясенең Юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту өчен заманча чараларны киң кертүне, үз-үзеңне хокуксыз тоту очрагында хокукый тәэсир итү чараларын эшләүне, шулай ук профилактик эшне камилләштерүне күздә тота.

Шәһәрләрдә транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары 2 номерлы кушымтада китерелгән.

Әлеге юнәлештә эшчәнлек транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең хәрәкәт шартларын яхшырту, транспорт агымнарын көйләүнең заманча ысулларын, юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын гамәлгә кертү, җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү, юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгуга юл шартларының йогынтысын киметү, урам-юл челтәренең үткәрүчәнлек сәләтен арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре күп булган урыннарда инженерлык чараларын үткәрүне күздә тота. Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар 3 номерлы кушымтада китерелгән.

Әлеге юнәлештә эшчәнлек юл-транспорт һәлакәте булган урынга аларның нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы хезмәтләрнең килү вакытын кыскартуны, аларның гамәлләре тизлеген һәм җайга салынуын, юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруны күздә тота.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү системасының норматив-хокукый, методик һәм оештыру нигезләрен камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар 4 номерлы кушымтада китерелгән.

Әлеге юнәлештә эшчәнлек юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә бердәм сәясәт эшләүне һәм формалаштыруны, юл-транспорт һәлакәтләренең килеп чыгуын билгеләүнең фәнни нигезләрен камилләштерүне, юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалауның өстенлекле юнәлешләрен нигезләү һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметүне, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы

системасы белән идарә итүнең оптималь модельләрен булдыруны, Программаны тормышка ашыру белән идарә итү һәм мониторинг системасын булдыруны, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерүне күздә тота.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны ресурс белән тәэмин итүне планлаштырганда район дәрәҗәсендә финанс-бюджет өлкәсендәге реаль хәл, авариянең торышы, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасының югары икътисади һәм социаль-демографик әһәмияте, шулай ук аны хәл итүнең реаль мөмкинлеге исәпкә алынды.

Программа чараларын финанслау җирле бюджет һәм юл хәрәкәте иминлеген финанслау дирекциясе чаралары хисабына башкарылачак.

2021 елда программаны финанслауның гомуми күләме**-4300,0 мең сум.**

«2021 елга Чирмешән муниципаль
районында юл хәрәкәте иминлеген
арттыру» район максатчан программасына
**1 нче кушымта**

**Юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын арттыруга**
**һәм куркыныч тәртибен кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар**

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| №№ | Чараның исеме | Башкару вакыты | Финанслауның гомуми күләме | Финанслау | | Башкару өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына | җирле бюджет чаралары хисабына | | |
| Башка ихтыяҗлар | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| 1. | «Игътибар-балалар!» , «Игътибар-җәяүле!» , «Әдәпле шофер», «Зебра» һ. б. киң күләмле акцияләр үткәрү. Мәгълүмат һәм реклама агентлыкларын юл хәрәкәтендә катнашучыларның дисциплинасын ныгытуга юнәлдерелгән профилактик акцияләр үткәрүгә җәлеп итү, материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга | 2021ел | 40,0 | 40,0 | - | «ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ» ДБУ | юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Балалар белән массакүләм чаралар үткәрү («Куркынычсыз тәгәрмәч» конкурс-фестивальләре, гомуми белем бирү учреждениеләре арасында балалар юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалау буенча конкурслар), ярышлар үткәрү, халык өчен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар үткәрү | 2021ел | 100,0 | 100,0 | - | «ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ» ДБУ | балаларда урамнарда һәм юлларда үз-үзеңне тоту күнекмәләрен формалаштыру |
| 3. | Яшь инспекторлар хәрәкәте слетын үткәрү, хәрәкәтнең яшь инспекторлары (ЮИД) хәрәкәтен үстерү | 2021ел | 30,0 | 30,0 | - | «ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ» ДБУ | балаларда урамнарда һәм юлларда үз-үзеңне тоту күнекмәләрен формалаштыру |
| 4. | Кече сыйныф укучыларының яктылык кайтаручы җайланмалары сатып алуы | 2021ел | 30,0 | 30,0 | - | «ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ» ДБУ | тәүлекнең караңгы вакытында балаларны таптату ихтималы киму |

«2021 елга Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» район максатчан программасына
**2 нче кушымта**

**Чирмешән муниципаль районында**
**транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары.**

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| №№ | Чараның исеме | Үтәлү вакыты | Финансланың гомуми күләме | Финанслау | | Башкару өчен җаваплы авыл җирлекләре | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына | җирле бюджет чаралары хисабына | | |
| 1. | Белем бирү һәм балалар бакчалары янындагы юл билгеләре, юл тамгалары белән урам-юл челтәрен төзекләндерү. | 2021ел | | - | 50,0<br>50,0<br>20,0<br>30,0<br><br>50,0<br>30,0 | Яңа Элмәле<br>Ивашкино<br>Түбән Кармалка<br>Мордва<br>Афонькәсе<br>Туймәт<br>Иске Үтәмеш | |
| 2. | Әйләнеш мәйданчыкларын норматив хәлгә китерү Мәктәп автобуслары маршрутларында павильоннар урнаштыру. | 2021ел | 12,500 | - | 12.500 | «Мәдәният бүлеге» МКУ | |

«2021 елга Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» район максатчан программасына
**3 нче кушымта**

**«2021 елга Юл хәрәкәте иминлеген арттыру» район максатчан программасын республика һәм җирле бюджетлар чаралары хисабына юнәлешләр буенча финанслау күләмнәре**

мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| Финанслау юнәлеше | 2021 ел (җирле бюджет чаралары, Барлыгы «ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ» ДБУ | Финанслау | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Җирле бюджет чаралары | ГГБУ «БДД» | Бюджеттан тыш финанслау |
| Хокукый аңны арттыру һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү | 200,0 | - | 200,0 | |
| Шәһәрләрдә Транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары | 4100,0 | 3100,0 | - | 1000,0 |
| Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү системасын үстерү | - | - | - | |
| Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү системасының норматив-хокукый, методик һәм оештыру нигезләрен камилләштерү | - | - | | |
| **Йомгаклау:** | **4300,0** | **3100,0** | **200,0** | 1000,00 |

«2021 елга Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» район максатчан программасына
**4 нче кушымта**

**Программаның дәүләт заказчылары арасында**
**«2021 елга Чирмешән муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән акчаларны бүлү**

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| Программаның дәүләт заказчылары | 2021 ел | |
|---|---|---|
| | капиталь кертемнәр | башка ихтыяҗлар |
| ГГБУ «БДД» | - | 200,0 |
| Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ | - | - |